КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 23 июнь г.Казань № 418

Россия Федерациясенең гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

«Гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр бирү буенча вәкаләтләрне тапшыру өлешендә Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 19 декабрендәге 461-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чаралары акчалата рәвештә бирелә дип билгеләргә.

2. Карарга теркәлгән Россия Федерациясенең гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен расларга.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чернобыль АЭСта, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге фаҗигада һәм Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынауларында нурланыш тәэсиренә дучар ителгән гражданнарга, шулай ук ветераннар һәм инвалидлар арасыннан гражданнарның аерым категорияләренә

торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру турында» 2005 ел, 26 гыйнвар, 39 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чернобыль АЭСта, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге фаҗигада һәм Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынауларында нурланыш тәэсиренә дучар ителгән гражданнарга, шулай ук ветераннар һәм инвалидлар арасыннан гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру турында» 2005 ел, 26 гыйнвар, 39 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 ел, 29 декабрь, 650 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 апрель, 167 нче карарының 2 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче карарының 4 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче карарының 7 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 12 март, 157 нче карарының 13 пункты.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\418.docx